***Мәктәп - туган җир җылысын бирүче, балачак һәм үсмер еллар истәлеген саклаучы, еллар дәвамында үзенә чакырып, ольлап каршы алучы изге йорт ул.***

***20 ел гомер....***

***Шушы елларда балалар укытуга зур өлеш керткән хөрмәтле ветеран укытучыларыбыз хәтирәләре***

## Юбилееӊ белән, гимназия!

Мәктәбебезнеӊ 20 ел элек ачылуы ботен Мөслим халкы өчен көтеп алынган шатлыклы вакыйга булды, чөнки укучылар ике смена-да белем алалар иде. Ул көн бик нык истә: мәктәбебез ачылуга беренче президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев үзе килде. Мәктәп капка төбеннән үк, матур итеп киенгән балалар кулларына чәчәкләр, шарлар, флагчыклар тотып, "тере" коридор ясап кунак-ларны каршы алдылар. Мәктәп эчендә укытучылар, укучылар кабинетларда кунакларны котеп торганы бүгенгедәй күз алдымда. Музыка кабинетында балалар президентыбыздан матур шигырь юллары белән бассейн сорап, бассейнлы булдык.

Дирекция членнары, коллектив эрудицияле, креатив, янып торалар иде. Бөтенесе дә ниндидер идеялар белән янып йөриләр.

Яӊа мәктәпне карарга кунаклар килү, ачык дәресләр, ачык чаралар бүгенгедәй күз алдымда. Әле кечә генә булган кебек. Рәхәт итеп эшләнде. Башта 3 нче мәктәп, аннары гимназия булса да берни үзгәрмәде, гел алдынгы булдык, алда бардык: районда да, республика күләмендә дә. Югары үрләр яулап, рәхәт, нәтиҗәле итеп эшләнде.

Мин шундый мәктәптә укытканыма бик сөенәм. Горурланам гимназия белән! Горурланам талантлы укучылары белән! Иӊ яхшы укытучылар, иӊ яхшы дирекция – гимназиядә!

***Зөлфирә Мөхәровна Саяхова***

*********

## Гимназия белән горурланып яшим

Яраткан хезмәтемнеӊ иӊ җаваплы, шул ук вакытта иӊ рәхәт булган унбиш елы шушында үткәнгәме, хәзерге вакытта 4 оныгым да шунда укыгангамы, бүгенге көндә Мөслим гимназиясе күӊелемә бик якын. Гимназиямдә булган саен, күӊелемдәге горурлык хисләре артканнан-арта бара.

Гимназиябез директоры Демидов Рафаэль Тимофеевич җитәкчелегендәге коллегаларым белән бергә, заманча бинаны тизрәк сафка бастыру максаты белән, төнгә кадәр җыештырып, дәртләнеп эшләп йөргәнгә 20 ел үтеп тә киткән. Күпме хатирәләр...

Гимназиябезне ачу көне бик кызык булып истә калган. Бу көнне без зарыгып, хәзерләнеп көттек. Район мәгариф бүлеге хезмәткәрләре белән класс кабинетларыныӊ хәзерлеген карап чыкканнан соӊ, директорыбыз Рафаэль Тимофеевич Республика президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймивны минем кабинетка алып керәчәген әйтте. Мин, әлбәттә, бик сөендем Президентыбыз белән бик аз вакытка гына булса да аралашу мөмкинлеге булачак ич. Укучыларым белән каршы алырга хәзерләнәбез: кунакларны ничек матур итеп каршы алырга, нинди сораулар бирергә... Үзем дә соравымны уйлап йөрим: "Президентыбыз тәүге хезмәт юлын башлаган Мослим сельхозтехникасындагы беренче көнен хәтерли микән? Аны беренче көнне каршы алган, үзенеӊ гаиләсендә фатир тапканчы кунак иткән оешманыӊ баш хисапчысын - бабам Софин Михаил Михаилович хәтерендә микән?" Соравыма җавап кына ала алмадым... Ашыккан прези-дентыбыз. Ә менә тышта "Җанлы коридор" да булганнар президент-ны күреп, аралашып калганнар. Шулай да мин үпкәләмим, киресенчә, горурланам.

Педагогик эшчәнлегемнеӊ иӊ җаваплы еллары гимназиядә эшләгән елларга туры килә: Мөслим районы башлангыч сыйныф укытучыларыныӊ методик берләшмәсе җитәкчесе дә, аттестация комиссиясе әгъзасы, эксперт та... Шуӊа күрә заман белән бергә атлап хезмәт итүче коллегаларымныӊ тәҗрибәсен тарату максаты белән республика, регион семинарларынын күбесен гимназиядә оештыру мөмкинлеге булды. Без, гимназиянеӊ башлангыч сыйныф укытучылары, үзебез артыннан район укытучыларын һәр яӊалыкка өйрәттек дию дә ялгыш булмас. Хәзерге федераль дәүләт белем бирү стандартларыныӊ нигезен тәшкил иткән иҗади үсеш технологиясен дә, мәгълүмати технологияне дә беренчеләрдән без куллана башладык, тәҗрибәбезне күрше республикаларга кадәр тараттык.

Бүгенге кондә күнелем кылларыныӊ иӊ тибрәткәне - араларында оныгым Сабина да булган соӊгы чыгарылыш укучыларым. Һәрберсе оныгым кебек бик-бик кадерле. Һәрбер укучымныӊ язмышы өчен борчылам. Әле кайчан гына нәни кулларыннан җитәкләп белем йортына алып кергән идем. 11 ел үтеп тә киткән, һәрбер укучыма уӊыш телим, һәрберсенә ышанам.

Мөслим гимназиясендә эшләвем белән бик горурланам. 15 ел эчендә киӊәшләшеп, бер-беребезне аӊлап эшләгән, хезмәтемә зур бәя биргән гимназия директорлары Демидов Рафаэль Тимофеевич, Насырова Нәкыя Мирзануровна, Мирзаянов Азат Фәритовичка тирән рәхмәтле мин. Гимназия бүгенгедәй һәрвакыт алгы сафта, гел үсештә булсын иде.

***Маргарита Александровна Идиятуллина***